# Ял сәгатьләрендә

***Сынамышлар***

*Февральнең беренче атнасында тотрыклы һава торышы сакланса, җәй озын яңгырлы булыр.
*Февральдә каен ботагында карлар алка-алка булып асылынып торса, ул елда иген уңар.
*Февраль карга бай, апрель суга бай.
*Февральнең беренче яртысында көннәр суык булса, арыш уңар; җылы булса, тары уңар.
*Февральдә бәс күп булса, агач җимешләре уңар, бал күп булыр.
*Февраль аенда кар күп булса, иртә җәйгә ишарә.
*Февраль ае ахырында кар күп яуса, борчак белән чикләвек уңар.
*Яз суык буласы булса, февральдә төлке эт кебек өрер, улар.
*Әгәр кышның бу ае буранлы икән, августта яңгыр көт, уҗым игене уңачак.
*Кар күп ятса, үлән калын булачак.
*Юлда кар калын, кырда юка булса, иген уңар.
*Көннәр белән бәйле халык сынамышлары:
*2 февраль иртә белән кар - ашлык иртә чәчкәне уңар; кич белән кар яуса - гаҗәп түгел соң чәчкәне уңса.
*3 февраль салкын булса, урак вакытында бик эссе булыр.
*7 февраль көннең беренче яртысы ничек булса, киләсе кышның беренче яртысы шулай булыр.
*8 февраль йолдызлы һәм аяз төн булса, гөмбә уңышы күп булачак.
*9 февраль агачлар бәскә төренсә - тиздән җылытачак.
*12 февраль ай кызарып торса, көчле җил булачак.
*14 февраль кук йолдызлы булса, яз соң килер.
*15 февраль көнне җепшек булса, яз иртә килер һәм җылы булыр
*26 февраль кар эресә, сулар акса, җәй яңгырлы булыр.
*27 февраль җылы һава булса, март аеның башы суык булачак.
*28 февраль боз сөңгеләре озын икән, яз да озын булыр.




## “БӘЙРӘМ ” САЛАТЫ



Салат өчен: 500 г пешкән тавык түше, 2 йомшак сыр, 3 пешкән кишер, 5 пешкән йомырка, 200 г каты сыр, майонез, яшел тәмләткечләр.

Эш тәртибе: йомшак сырны, йомыркаларны һәм кишерне угычтан уарга, майонез белән болгатырга. Тәлинкәгә бер кат туралган тавык ите, икенче кат алдан ясаган катнашманы җәяргә, бу катламнарны бернichә тапкыр кабатларга. Әзер салатка каты сыр уарга, бизәргә һәм 1 сәгать суыткычта тотарга.




**Газетаны оештыручылар һәм редколлегия әгъзалары:** татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әхмәтгалиева Эльмира Алис кызы һәм Мифтахетдинова Фирдания Ансар кызы.

**Индекс-** 422020

**Адрес:** ТР, Арча муниципаль районы ,Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 йорт.

МБОУ «Ново-Кырлайская СОШ имени Г.Тукай»
МБГБУ «Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе»

Февраль, 2026
№ 6

# ЧИШМӘ БАШЫ

2026 ел Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы.

### Бәйрәм белән, хөрмәтле Ватанны саклаучылар!

Һәр халыкның үз тарихында мөһим урын алып торган, буыннан-буынга тапшырыла торган бәйрәмнәре бар. Аларның берсе – 23 нче февраль, Ватанны саклаучылар көне. Бу көн – ир-атларның батырлыгын, ныклыгын, Ватанга тугрылыгын гәүдәләндерүче, шулай ук хатын-кызларның да үз Ватаны өчен фидакарь хезмәт итүен искә төшерүче мөһим дата.

**Тарихка бер караш:**

Бу бәйрәмнең тамырлары 1918 елга барып тоташа. Беренче бөтендөнья сугышы чорында, яңа оешкан Совет дәүләте алдында зур куркыныч янаганда, Кызыл Армиянең беренче отрядлары немец гаскәрләренә каршы тора. Нәкъ менә шул вакыйгалар, аеруча Псков һәм Нарва янындагы сугышлар, бу көнне Кызыл Армиянең туган көне итеп билгеләүгә нигез сала. Башта "Кызыл Армия көне" дип аталган бәйрәм, соңрак "Совет Армиясе һәм Хәрби-Диңгез Флоты көне" дип үзгәртелә. Советлар Союзы таркалганнан соң, ул "Ватанны саклаучылар көне" дип атала башлады һәм үзенең әһәмиятен югалтмады, киресенчә, яңа мәгънәләр белән баеды.

**Бүгенге көндә 23 нче февраль:**

Хәзерге вакытта 23 нче февраль – ул инде бары тик хәрби хезмәткә кагылышлы гына бәйрәм түгел. Ул – Ватанны яклаучы, аның иминлеген кайгыртучы һәр ир-атның, һәр гражданинның көне. Бу көнне без Ватаныбызның тынычлыгын һәм иминлеген саклаучыларга – ветераннарга, хәрби хезмәткәрләргә, шулай ук киләчәктә Ватанны саклау бурычын үтәячәк яшь буынга хөрмәт күрсәтәбез. Бу көн – яшьләргә патриотизм, гражданлык бурычы, батырлык кебек сыйфатларны тәрбияләү өчен менә дигән мөмкинлек. Мәктәбебездә дә шушы бәйрәм уңаеннан күп кенә чаралар узды: мәктәбебезнең ир-атларын, этиләребезне бәйрәм белән котладык, махсус хәрби операция батыры Аглиев Алмаз Хәмит улы истәлегенә багышланган “Строевой смотр” узды.







# Изгелек кылырга ашык!

Мәктәбебез коллективы: укучылар, укытучылар, техник хезмәткәрләр, әти-әниләр, #МЫВМЕСТЕ акциясендә катнашуыбызны дәвам итәбез. Без СВО сугышчыларына маскировка челтәрләре үрү өчен махсус тукыманы буй-буй кисеп, әзерлек эшләре алып бардык. Барыбыз бергә зур игелекле эш эшлибез. Аның һәр ячейкасына игелек һәм мәхәббәт үрелә, шуңа күрә мондый саклану теләсә кайсы бронядан да ышанычлырак.

Бүген махсус хәрби операциядә катнашучыларга, якташларыбызга, туганнарыбызга һәм якыннарыбызга ярдәм күрсәтүдә бердәм команда булу бик мөһим. Һәркем зур эшкә үз өлешен кертә һәм бары тик уртак тырышлык белән генә без кемнеңдер гомерен саклап кала алабыз.





## 2 февраль безнең илдә Россиянең хәрби даны көне



2 февраль безнең илдә Россиянең хәрби даны көне – 1943 елда совет гаскәрләренең Сталинград сугышында немец-фашист гаскәрләрен тар-мар итү көне билгеләп үтелә. Бу – илнең героик елъязмасына мәңгегә кертелгән дата. Сталинград сугышы – Бөек Ватан сугышының хәлиткеч сугышларының берсе. 200 көн һәм төн дәвам иткән каты сугышлар рус гаскәрләренең хәлиткеч җиңүе белән тәмамланды. Ә Сталинград рус армиясенең ныклыгы, рус солдатының батырлыгы символына әверелде. Сталинград сугышында Җиңүнең 83 еллыгына багышлап 9-10 сыйныфларда Хәтер дәресе үткәрелде. Дәресне тарих укытучысы Шигапова Г.Х. үткәрде.

Ул укучыларны бөек халык батырлыгы, Сталинград шәһәрен саклаучыларның бердәмлеге һәм батырлыгы, Сталинград сугышының икенче бөтендөнья сугышының иң зур сугышларының берсе булуы, сержант Павлов йорты турында, анда 58 көн дәвамында совет сугышчылары төркеме героик рәвештә оборона тотканлыгы, Мамай курганы – «Ватанның төп биеклеге» турында, анда иң каты сугышлар барганлыгы һәм Сталинград өчен иң кайгылы көн 1942 елның 23 августы булганлыгы, ул вакытта массакүләм бомбага тоту нәтиҗәсендә шәһәрдән хәрабәләр генә калганлыгы һәм 40 000 тыныч халык һәлак булганлыгы турында таныштырды. Шулай ук укучылар Сталинград сугышында катнашкан авылдашларының исемнәрен белделәр һәм аларның хәтерен искә алдылар



Юнармиячеләр дә Икенче бөтендөнья сугышы барышында төп борылыш ясаган Сталинград сугышы турында сөйләделәр. Директорның тәрбия эшләре буенча киңәшчесе Шакирова И.М. җитәкчелегендә «Россия өчен сугыш. Сталинград сугышы. Чуйков Паулюска каршы» документаль фильмын карау оештырылды. Документаль фильмны караганнан соң, балалар Сталинград фашизм өстеннән хәрби һәм әхлакый өстенлек, шулай ук халкыбызның бөек батырлыгы символы булып кала һәм калачак дигән нәтиҗәгә килделәр!



## Укытучылырыбызның уңышлары



Казанның Совет районы 11 нче номерлы татар гимназиясендә Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов исемендәге "Дөньяда сүзебез бар…" дип исемләнгән II Халыкара фәнни-гамәли конференция булып үтте. Әлеге конференциядә укытучыларыбыз Гайфуллина Л.Х. һәм Шакирова И.М., Шиһапова Г.Х., Зарипова М.Р. һәм 10 сыйныф укучысы Ганеева Алинә (җитәкчеләре Ганеева  Котлыйбыз аларны, киләчәктә дә уңышлар телибез!





20 февраль көнне Казан шәһәренең 80 нче номерлы мәктәбендә уздырылган Насыйри укуларында 11 класс укучысы Хәйретдинов Аяз (җитәкчесе Кабирова Әнисә) һәм укытучыларыбыз Сәләхова Илгизә, Шиһапова Гөлгенә уңышлы чыгыш ясап призлы урыннарга ия булдылар.

Г.



Мәктәбебезнең башлангыч класс укытучылары Фатихова Сәрия Дамир кызы, Камалиева Рәмзия Мәдрәсүл кызы 16 февраль көнне Казанның 125 номерлы гимназиясендә үткәрелгән V Республикакүләм "От идеи до результата-2026" фестивалендә чыгыш ясады

## Татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча олимпиадада җиңү – Илүзә Хайдарованың зур уңышы!



Безнең республикабызның яшь буынының тарихыбызга, халкыбызның бай мирасына тирән кызыксынуы һәрвакыт сөендерә. Менә тагын бер шатлыклы хәбәр - 9 нчы сыйныф укучысы Хайдарова Илүзә, татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча узган республика олимпиадасында җиңү яулап, призер булды! Бу – Илүзәнең һәм укытучысы Шиһапова Гөлгенә Хәсбиулла кызының зур тырышлыгы. Илүзәнең зирәклеге һәм туган ягы тарихын тирәнтен өйрәнүгә булган омтылышының лаеклы бәясе.



Татар телендә белем бирүче мәктәп укучылары өчен татар әдәбиятыннан республика олимпиадасының йомгаклау этабы узды. Мәктәбебезнең 7 класс укучысы Сабирова Алсу, 9 класс укучысы Хайдарова Илүзә һәм 10 класс укучысы Ганеева Алинә призер исемнәрен яуладылар. Кызларыбызны зур уңышлары белән чын күңелдән котлыйбыз! Аларның әзерлегендә зур хезмәт куйган укытучыларыбыз Зарипова М. Р. һәм Ахметгалиева Э. А.га рәхмәтләребезне белдерәбез.

# Батырларның даны мәңгелек

**Тере тарих - Әфган сугышы ветераннары белән очрашу**

Ватанны саклаучылар көне алдыннан һәм хәрби-патриотик айлык кысаларында мәктәбебездә "Вакыт Сезне сайлады..." дигән батырлык дәресе – класс сәгате узды. 7-11 сыйныф укучылары алдында мәктәбебезнең Әфганстанны үткән чыгарылыш укучылары Яруллин Илнур Гомәр улы, Сабиров Данаил Рамазан улы, Хәсәнов Фәрит Рудил улы, Кавиев Фердинанд Дәүләт улы, тарих укытучысы Шиһапова Гөлгенә Хәсбиулла кызы һәм безнең юнармиячеләр чыгыш ясады. Алар балаларга Әфган сугышы һәм башка локаль сугышлар турында хәтердә саклауның әһәмиятен житкерделәр, хезмәт еллары, батырлык һәм иптәшлек турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар, Ватанны яратуның һәм аны якларга әзер булуның никадәр мөһим булуы турында сөйләделәр.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, Яруллин Илнур Гомәр улы шулай ук актив волонтер, "Үзебезнекеләрне ташламыйбыз" җәмгыяте рәисе булып тора һәм даими рәвештә безнең сугышчыларга махсус хәрби операция зонасына гуманитар ярдәм илтә. Ул, волонтерлар эшчәнлеге турында сөйләде, гуманитар ярдәм өчен рәхмәт белдерде һәм хәрбиләрнең балалар язган открыткаларын, хатларын дулкынланып укуларын, туганнарның һәм бөтен җәмгыятьнең әхлакый ярдәмнең солдатлар өчен бик мөһим булуын әйтте.

Бу чара мәктәп укучылары өчен мөһим вакыйга булды, хәрби тормышның авырлыклары һәм хәрби хезмәткәрләр очрашкан кыенлыклар турында белү мөмкинлеге бирде.
Мондый очрашулар үз илең өчен горурлык хисе тәрбияләүгә ярдәм итә. Укучылар чын геройларның янәшәдә яшәвен, батырлык, кыюлык, Ватанга мәхәббәт – чын кешенең сыйфатлары нинди булуын күрделәр.

Геройлар безнең арада! Саклаучыларыбыз белән горурланабыз!





**Муса Җәлилнең тууына 120 ел**

15 февральдә бөек шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулды. Муса Җәлил – үзенең патриотик шигырьләре белән милләтебезнең горурлыгы һәм рухи байлыгы булып калган шәхес. Ул үз иҗаты аша Ватанга мәхәббәт, батырлык һәм намус кебек кыйммәтләрне чагылдыра.

Шул уңайдан мәктәбебездә һәм китапханәдә "Муса Җәлил иҗатын өйрәнәбез" дип исемләнгән әдәби кичәләр уздырыла. Шулай ук укучыларыбыз "Муса Җәлил - патриотик шагыйрь" әдәби марафонына кушылдылар.









**21 нче февраль Халыкара туган тел көне**




Туган тел – ул безнең җаныбыз, иң кадерле мирасыбыз. Ул безгә ата-бабаларыбыздан күчеп килгән, күңелебезгә җылы бирә торган иң якын тел. Һәр кеше өчен туган тел – үзенең шәхесен, тарихын һәм мәдәниятен саклаучы иң мөһим байлык.

21 февраль – Туган телләр көне буларак билгеләп үтелә. Бу көнне без туган телебезнең матурлыгын, байлыгын һәм әһәмиятен искә алабыз, аны саклау һәм үстерү кирәклеген аңлыйбыз. Яраткан язучыбыз Фәнис Яруллинның шундый сүзләре бар: «Тел - халык күңеленең кыңгыравы. Ә кыңгырау кагылмасаң чыңламый». Кыңгырау гел чыңлап торсын өчен, тел югалмасын өчен үз телеңдә сөйләшергә кирәк.

Һәр халыкның теле үзенчәлекле, күп телләр белү дөньяга карашны киңәйтә, төрле милләт халкының мәдәниятен тирәнрәк белергә ярдәм итә. Ләкин һәркемнең дә туган теле бер генә. Шуңа күрә һәр милләт кешесе үз телен яратырга һәм башка милләтләрнең теленә хөрмәт белән карарга тиеш.

Безнең мәктәп китапханәсендә дә бу мөһим дата уңаеннан әңгәмәләр оештырылды. Анда катнашучылар туган телнең нечкәлекләре, аның матурлыгы турында фикер алыштылар, үзләренең яраткан шигырьләрен укыдылар. Шигырьләр аша телнең җанлы, хисле һәм тирән мәгънәле булуы аеруча ачык күренде.

Мәктәбебездә уздырылган чаралар барышында да шигырьләр, әйтемнәр, киңәшләр белән телгә сөю - ихтирам, аны саклау-яклау өчен бердәм көчнең кирәклеге ассызыкланды. Мондый чаралар телебезне саклау, ярату һәм хөрмәт итү мөһимлеген искә төшерү максатында кирәк. Туган телләребезне саклыйк, яклыйк, чөнки милләтнең яшәешендә туган тел иң мөһим урыннарның берсен алып тора. Туган тел дигән күңел кыңгыравыбыз мәңге чыңласын иде дигән теләктә калабыз.







## "Арча йолдызлары - 2026"




Мәктәбебезнең 10 класс укучысы Исмәгыйлова Адилә "Арча йолдызлары - 2026" эстрада җырлары конкурс-фестиваленең сайлап алу турын уңышлы узды. Җитәкчесе Шарафетдинова Г.Н. җитәкчелегендә Адилә үзенең талантын күрсәтте һәм киләчәктә дә зур уңышларга ирешер дип ышанабыз. Алга таба да укучыбызга иҗади уңышлар һәм яңа үрләр телибез!

Исмәгыйлова Адилә үзенең сәләте һәм тырышлыгы белән мәктәпебезнең горурлыгы булып тора. Аның җырлаудагы осталыгы, сәхнәдәге үз-үзен тотышы һәм музыкаль зәвыгы һәркемнең игътибарын җәлеп итә. Конкурс-фестивальләрдә катнашу аңа яңа тәҗрибә һәм мөмкинлекләр ача, иҗади үсешенә этәргеч бирә. Безнең коллектив һәм укучылар арасында мондый уңышлар рухны күтәрә, яшь талантларга үрнәк булып хезмәт итә. Алга таба да Адиләгә иҗат юлында зур уңышлар, яңа иҗади идеяләр һәм тормышында бәхет телибез. Аның тырышлыгы һәм максатчанлыгы киләчәктә дә үз нәтиҗәләрен бирәчәк, һәм без аның яңа җиңүләрен түземсезлек белән көтеп калабыз. Мәктәбебезнең барлык укытучылары һәм укучылары Адиләгә һәрвакыт ярдәм күрсәтергә әзер, чөнки безнең өчен һәр талантлы укучы – мәктәпнең киләчәге һәм горурлыгы.

## "Тату сыйныф серләре" республика конкурсы

Республикабызның һәр почмагында “Тату сыйныф серләре” дип исемләнгән зур бәйге барды. Бу чара аеруча яшь буын арасында зур кызыксыну уятты. Конкурсның төп максаты – укучыларның сыйныфташларына, укытучыларына һәм мәктәпкә булган уңай мөнәсәбәтләрен, бердәмлекләрен, ярдәмләшү рухларын чагылдырган иҗади эшләрне ачу.

Безнең 5 сыйныф укучылары да һәм аларның әти-әниләре, сыйныф җитәкчесе Мифтахова Гөлнар Гарифҗан кызы белән берлектә "Тату сыйныф серләре" республика конкурсының район этабында чыгыш ясадылар. "Без Тукайлы халык" дигән темага күргәзмә оештырдылар. Әлеге чараны әзерләүдә ярдәм иткән һәм чыгыш ясаган укучыларга, сыйныф җитәкчесенә, әти-әниләргә, педагог-оештыручы Шәрәфетдинова Г.Н., Гайфуллина Л. Х.га,Шакирова И. М.- тәрбия бирү буенча директор киңәшчесенә, укытучыларга олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

Һичшиксез, мондый конкурслар укучыларның күңелләрен берләштерүгә, араларындагы дуслыкны ныгытуга, уңай мохит булдыруга зур өлеш кертә. “Тату сыйныф серләре” конкурсы – ул җиңүчеләрне генә түгел, ә барлык катнашучыларны да бәхетле итүче, аларга иҗат чикләрен киңәйтү мөмкинлеге бирүче бәйрәм.





## Мәктәптә ата-аналар җыелышы узды



Мәктәбебездә ата-аналар җыелышы булып узды. Очрашуда укучыларның укуга карашы, имтиханнарга әзерлек һәм тәрбия эшчәнлеге кебек мөһим мәсьәләләр каралды.

Тәрбия эшчәнлеге җыелышның мөһим өлеше булды. Мәктәптә үткәрелә торган тәрбия чаралары, балаларның социальләшүе һәм шәхес булып формалашуы турында сөйләштеләр. Ата-аналарга балаларның әхлакый тәрбиясендә гаиләнең роле, мәктәп белән хезмәттәшлекнең әһәмияте аңлатылды.



# Мәктәп тормышы

## Спорттагы уңышларыбыз


Арча Укучылар сараенда узган "Иң яхшы шашист - 2026" шашка ярышының 1 этабында укучыларыбыз яхшы уен күрсәтте:
2 класс укучылары: Фазылҗанова Айсылу - 1 нче, Гайфуллин Раяз -2 нче, 5 класс укучысы Шакиров Инсаф, 8 класс укучысы Шакиров Булат - 1 нче урыннарны яуладылар. Командага 2 урын (Тренерлары Шакиров И. З.) Укучыларыбызны уңышлары беоән котлыйбыз! Калган этапларда да уңышлар телибез.

2 класс укучысы Хәйруллина Хадиджа Арчада бөтенроссия "Лыжня России -2026" ярышында 1 нче, Сабада узган ярышта 2 нче урынны яулады. Укучыбызны котлыйбыз! Алга таба да уңышлар телибез.









Мамадыш шәһәрендә Татарстан беренчелегенә узган волейбол ярышларында Арчаның җыелма командасы 3 урынга лаек булды. Мәктәбебезнең 8 класс укучыларына: Авхадиева Алиягә, Закирова Илүзәгә, Минуллина Язиләгә, Фатыхова Адиләгә тагын да зуррак уңышлар телибез Афәрин, кызлар. Тренерлары Амиров Нияз Асхатович.




Арча Укучылар сараенда узган "Иң яхшы шашист - 2026" шашка ярышының 1 этабында укучыларыбыз яхшы уен күрсәтте
2 класс укучылары: Фазылҗанова Айсылу - 1 нче, Гайфуллин Раяз -2 нче, 5 класс укучысы Шакиров Инсаф, 8 класс укучысы Шакиров Булат - 1 нче урыннарны яуладылар. Командага 2 урын (Тренерлары Шакиров И. З.) Укучыларыбызны уңышлары беоән котлыйбыз! Калган этапларда да уңышлар телибез.




28 февраль көнне Теләченең "Батыр" спорткомплексында 2011 нче елгы һәм аннан яшьрәк яшүсмерләр арасында Татарстан Республикасы билбау көрәше федерациясе рәисе, Казан шәһәре көрәш федерациясе җитәкчесе, Зилант спорт клубы җитәкчесе, "Интерметтрейд" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, милли көрәш буенча Татарстанның спорт остасы Габдрахманов Расих Әхмәт улы призларына милли көрәш буенча ачык Теләче муниципаль районы беренчелеге узды.

Арча командасы составында, катнашкан 8 класс укучыбыз Минуллин Раяз үз үлчәмендә урынга лаек булды. Тренеры Саляхов М. Р